Сайт школы:
http://kazan33.ru

# ШКОЛА РАДОСТИ

Издается
с 2009 года

№9 (119) 2021

• ГАЗЕТА МБОУ «ГИМНАЗИЯ №33» АВИАСТРОИТЕЛЬНОГО РАЙОНА г. КАЗАНИ •

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МӘҢГЕ БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛЛӘРДӘ...

Габдулла Тукай 1886 нчы елның 26 нчы апрелендә Кушлавыч авылында туган. Габдулланың башта әтисе, аннары дүрт яшендә әнисе вафат була. Шулай итеп, ул бик яшьли ятимлек ачысын тоя. Шагыйрьнең “Исемдә калганнар” исемле автобиографик әсәре аның балачакта күргән кимсетүләре, кайгылары турында язылган. Ятим, ярлы баланы гаиләдән гаиләгә күчереп йөрткәннәр.



Бары тик 1895 нче елны гына ул Җаек (Уральск) шәһәрендәге ерак туган апасының гаиләсенә килеп керә. Бу гаилә булачак шагыйрьгә яшәү өчен шартлар тудыру белән бергә, аның белеме турында да кайгырта – Габдулла мәдрәсәдә укый, рус телен өйрәнә. Унтугыз яшендә ул русчадан татарчага тәрҗемә итә башлый, шул вакытта беренче шигырьләрен яза.

Габдулла Тукай балалар өчен бик күп әкиятләр һәм шигырьләр язган. Аның “Су анасы”, “Шүрәле” әкиятләрен кем генә белми икән!

Кызганычка каршы, Габдулланың яшьли курган газаплары эзсез узмый – ул каты авырый һәм нибары 27 яшендә вафат була. Ләкин шул кыска гына гомерендә дә ул безгә зур әдәби мирас калдырган. Бүгенге көндә дә Тукайның әсәрләре мәктәпләрдә өйрәнелә, шигырьләренә җырлар языла.

Габдулла Тукай – безнең халкыбызның горурлыгы! Ул үзе дә, аның иҗаты да мәңге онытылмасын иде!

**Зәринә ЗАГРЕЕВА, 7 “А”**





*Газетабызның бу махсус саны татар халкының бөек шагыйре **Габдулла Тукайның туувына 135 ел тулуга** багышланган.*

*Укучыларыбызның иҗатын рәхәтләнеп укыгыз!*

## БУ САНДА:

2 бит ТУКАЙ ИҖАТЫ БЕЗНЕ НӘРСӘГӘ ӨЙРӘТӘ?
3 бит ИҢ ЯРАТКАН ӘСӘРЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ГЕРОЙЛАРЫ
4 бит ИЛҺАМ КАНАТЫНДА

# ТУКАЙ ИҖАТЫ БЕЗНЕ НӘРСӘГӘ ӨЙРӘТӘ?



Мин татарча китаплар укырга, мультфильм һәм телевизион тапшырулар карарга яратам. Шулар арасында иң яратканы – ул сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның әкиятләрен уку.

Тукай әкиятләрен укыганда, син үзеңне бөтенләй башка дөньяда хис итәсең. Тукайның Су анасы, Кәҗә белән Сарыгы, Шүрәлесе, Кисекбашы белән бергә яшисең... Су анасының тарагын урлаган малайга карата синдә нәфрәт, бармагы бүрәнәгә кысылган Шүрәлесенә карата кызгану хисе туа.

Тукай әкиятләре безне кешелекле булырга, алдашмаска, табигатебезне сакларга өйрәтә. Шуңа күрә аларны олысы да, кечесе дә яратып укый һәм белә.

**Нәргизә ИБРАҺИМОВА, 6 “Б”**

******

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның иҗатын белмәгән кеше юктыр. Ул безгә үлмәс әсәрләр калдырган. Ул безне акыллы, тыйнак, гадел булырга өйрәтә, табигатьне, анда булган бар тереклекне яратырга өнди. Аның әдәплелеккә, бөеклеккә, тәүфыйклылыкка өндәгән шигырьләрен һич онытырга ярамый. Нинди генә шигырьләрен укыма, гади, аңлаешлы, хәтердә кала торган. Аның әсәрләре шулкадәр кызыклы!

Тукай татар милләте, татар халкы күңелендә бүген дә яши һәм яшәячәк! Аның иҗаты беркайчан да онытылмас, чөнки ул – бөек шагыйрь!

Кемдер аңа карап соклана, кемнәрдер үрнәк итеп, аны бүгенге көннәрдә дә үз йөрәгендә йөртә. Мин дә Габдулла Тукай иҗатын бик яратып укыйм, күп нәрсәгә өйрәнәм.

**Камилла ХӘЙРУЛЛИНА, 7 “А”**

******

Габдулла Тукай... Безнең арада бу олы шәхес турында ишетмәгән, белмәгән кеше бар микән? Юктыр... Аның турында ишеткәч, күңелдә төрле хисләр туа.

Башлангыч сыйныфта укыганда ук “Туган тел” шигырен ятлап, “Су анасы” әкиятен укып, шагыйрьнең ачы язмышы белән танышкан идек. Тукайның тормышы чын мәгънәсендә тетрәндергеч, беркемне дә битараф калдырмый торган. Нәни Габдулла ата-анасын югалта, ятим кала. Өйдән-өйгә, кулдан-кулга күчә ул. Ләкин бернинди дә сынауларга бирешми, тормышыннан зарланмый...

Якты дөньядан китеп барганда Тукайга 27 яшь кенә булган. Шулай булуына карамастан, шагыйрь безнең йөрәкләргә мәңгегә кереп калган. Бөек Тукай безгә үлмәс иҗатын калдырган. Аның һәр әсәре гади, ләкин шул ук вакытта тирән мәгънәле.

Тукай рухы яшәгәндә, Тукай моңнары яңгыраганда татар милләте, аның теле яшәр, киләчәге якты булыр, минемчә.

**Алинә ШАРАФЕЕВА, 7 “Г”**



# ИҢ ЯРАТКАН ӘСӘРЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ГЕРОЙЛАРЫ

Габдулла Тукайның бик күп әкиятләре бар. Хәзерге вакытта шул әкиятләр буенча төшерелгән мультфильмнар да күп. Без аларны татар теле дәресендә карыйбыз: “Су анасы”, “Эш беткәч уйнарга ярый”, “Шүрәле”, “Кәҗә белән Сарык”.



Минем иң яраткан әкиятем “Кәҗә белән Сарык”. Кечкенә чакта йоклар алдыннан миңа әнием сөйли иде аны. Миңа бу әкиятнең төп геройлары ошый, чөнки алар батыр булганнар һәм бүреләрдән курыкмаганнар.

Тукай әкиятләрендәге барлык геройлар да балаларны яхшы, акыллы, тәртипле булырга өйрәтә. Үземнең яшьтәшләремә Тукай әсәрләрен укырга тәкъдим итәм.

**Алия ФӘЙЗУЛЛИНА, 2 “Б”**

******

Габдулла Тукай – татар мәдәниятенең иң якты һәм күренекле вәкилләренең берсе.


Ул татар халкының күп кенә буыннарның йөрәгендә кала торган матур әсәрләрне иҗат иткән шәхес. Нәкъ менә аннан татар гореф-гадәтләре һәм йолалары башлана, Габдулла Тукайны татар җәмгыятендә сөйлиләр һәм бик яраталар.

Минем фикеремчә, без әлеге язучының истәлеген төрле юллар белән сакларга тиеш: әсәрләрен укырга, тормышындагы мөһим вакыйгаларын истә тотарга, шигырьләрен өйрәнергә һәм аларны киләчәк буыннарга тапшырырга. Моның өчен мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты дәресләре укытыла, анда без Габдулла Тукай иҗаты белән танышабыз.

Минем өчен иң яраткан әсәрләренең берсе “Исемдә калганнар” булды. Бу хикәяне укып, мин хәтта еладым да, язучының авыр тормышын кызгандым. Минемчә, бу аның иң көчле әсәре!

Зинһар, Габдулла Тукай турында онытмагыз һәм аның әсәрләрен укуны дәвам итегез!

**Ильвина ШАКИРОВА, 7 “А”**



******

Бу уку елында без Габдулла Тукайның “Шүрәле” поэмасын өйрәндек.

Моңа кадәр мин Шүрәлене бары тик тискәре образ буларак кына күз алдына китерә идем. Бармагы бүрәнәгә кысылган Шүрәленең урман буйлап



чабып йөрүеннән кызык табып көлә идем. Хәзер исә аның урманны саклавын – урманның хуҗасы булуын аңладым. Шүрәле миндә кызгану хисе уятты. Кешеләрнең явызлыгына Шүрәленең беркатлылыгын каршы куеп, ничек оста тасвирлаган аны бөек Тукаебыз.

Тукай әкиятләрен күбрәк укыган саен авторның сурәтләү осталыгына таң каласың, шуңа күрә аның китаплары күпләрнең өстәл китабы булып тора да.

**Әминә СИБГАТУЛЛИНА, 6 “А”**

******

Тукайның иҗаты күпкырлы, бай. Ул балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә язган. Аның “Шүрәле”, “Су анасы” поэмалары – могҗизалы да, серле дә. Син әкияти геройлар белән танышасың. Шул ук вакытта балаларны яхшы гадәтләргә өйрәтә. Акыллы, гадел, тыйнак, әдәпле, бар тереклекне яратырга өнди автор.

Ул үзенең иҗатында татар халкын бердәм булырга, үз телен, илен хөрмәт итәргә чакыра. Г. Тукай - ул татар халкының горурлыгы, алга өндәүче маягы булып тора!

**Альмир ГАЛИЕВ, 7 “А”**

# ИЛҺАМ КАНАТЫНДА
## (ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ИҖАТЫ)



**Тукай шигырьләрен укыйм**
Тукай шигырьләрен укыйм,
Кечкенәдән яратып.
Су анасын, Шүрәлене
Тәрәзәмнән каратып.
Кәҗәсенә печән бирәм,
Мин Гали булам бүген.
Үскәч Былтыр булырмынмы?
Әйтә алмамын бүген.
Алтын тарагын урламам
Су анасының, беләм.
Тукай шигырьләрен ятлыйм,
Чын күңелемнән менә.
Тукай шигырьләре миңа
Матурлыкны күрсәтә.
Алар мине яхшылыкка,
Тырышлыкка өйрәтә.
**Хәсән ЛОТФУЛЛИН, 6 “Б”**

******

**Безнең “Кәҗә белән Сарык”**
Кәҗә белән сарык яши
Әби белән бабамда.
Тукай әкиятләрен сөйлим,
Кайткач шулай аларга.
Алар мине аңлый кебек,
Күзләремә карыйлар.
Бүредән курыкмабыз дип,
Кулларымны ялыйлар.
Бабай печән белән сыйлый,
Әби тәмле он бирә.
Мин шифалы су эчерәм,
Сеңлем шатлыктан көлә.
Аларны бик яратабыз,
Көн дә карыйбыз бергә.
Алар Тукай бабабыздан
Килгән кунак бит безгә.
**Хәсән ЛОТФУЛЛИН, 6 “Б”**

******

С детства мы помним сказки Тукая -
В каждой есть мудрость и добрый совет.
Гордость родного нашего края
Тукай – великий татарский поэт!
**Алия ЗАГИДУЛЛИНА, 5 “В**

******

Не уставая, вкладывая душу,
Он писал стихи и сказки.
Недаром день рождения Тукая
Великий праздник и
прекрасный!
**Мария ЛУЦЕНКО, 5 “В”**

**Жив Тукай в сердцах людей!**
Жил Тукай на землях наших -
Уж прошло немало лет.
Сказки мы его читаем,
Дни рождения отмечаем,
Помним мы его и знаем,
Что талантом был большим!
Был еще и человеком
Простым, как мы.
Стихи писал, и жить хотел!
Ходил по улицам, где ходим мы сейчас
И думаем о нем: что рано так пробил
Твой скорбный час.
Жизни земной отведено
Двадцать шесть лет всего!
У аула лес зеленый,
И куча сказок в том лесу.
И днем, и ночью Шурале
Все ходит по лесу кругом.
Идет направо всех щекотит,
Налево всех пугает он.
И много сказочных существ
Живут в лесу Тукая том.
Да, жив Тукай в сердцах людей,
У пожилых, и у детей!
Шурале его живет, и Водяная тоже,
Гали, Коза, смешной Щенок,
Бабочка, что день всего лишь может,
Мальчик, что уроки учит,
Яблоня в окно стучит,
И Солнышко поможет.
Тукай! Хоть на Земле так мало жил,
Но в сердце каждого из нас
Ты будешь жить в веках!
Ты жив, поэт, и будешь жить
И в сказках, и в стихах!
**Лилия ШАГИМАРДАНОВА,**
**Арина КУЗЬМИНА,**
**7 “В”**

ШКОЛА РАДОСТИ
**Главный редактор:** Файзуллина Л. Ф.
**Редколлегия:** Мусаяпова Н.Х., кафедра учителей родного языка и литературы
Тираж 100 экз.
**Адрес редакции:** 420037, РТ, Казань, ул. Симонова, д. 17, ПРЕСС-ЦЕНТР
**Телефон редакции:** 8 (917) 247-60-30
**E-mail:** lyaisan1985@mail.ru